**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТУТАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

2020 ел, 2 ноябрь № 9

**«Тутай авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә һәм Тутай авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга муниципаль вазыйфадан пенсиягә чыгу сәбәпле бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкне түләү тәртибе турында» гы карарга үзгәрешләр кертү турында**

2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Тутай авыл җирлеге Советы карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Тутай авыл җирлеге Советының 2018 елның 18 маендагы 92 номерлы «Тутай авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга һәм Тутай авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга муниципаль вазыйфадан пенсиягә чыгу сәбәпле бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтада

1.1 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Нигезләмәнең максатлары өчен тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу дигәндә, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 28 статьясындагы 1 өлешендә каралган нигезләр буенча, «иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясен алу хокукын бирә торган яшькә җиткәч я вакытыннан алда картлык буенча иминият пенсиясен яисә инвалидлык буенча иминият пенсиясен билгеләгәндә һәм тиешле елларны эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен кирәкле муниципаль хезмәт стажы булганда, муниципаль хезмәттән азат ителү аңлашыла.»;

1.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«1.7.Бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү күләмен билгеләү өчен, муниципаль хезмәткәр җирлек Башкарма комитетына (килешү буенча) (алга таба – Башкарма комитет) түбәндәге документларны тапшырырга:

муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата түләүе турында белешмә;

муниципаль хезмәттәге эш стажы турында җитәкче һәм кадрлар хезмәткәре тарафыннан раслаган белешмә;

хезмәт кенәгәсенең күчермәсе, тиешенчә расланган һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66.1 статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган белешмәләр;

кадрлар хезмәте раслаган хәрби билетның күчермәсе (муниципаль хезмәткәдә булган очракта);

классны чин бирү, муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата кереме составына керүче вазыйфаи окладка өстәмәләр билгеләү турында күрсәтмәләрдән өземтә;

муниципаль хезмәткәрнең эш стажын билгеләү өчен законнар нигезендә кирәкле башка документлар.»;

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Тутай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Апас муниципаль районы Тутай авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Апас муниципаль районы**
**Тутай авыл җирлеге Башлыгы,**
**Апас муниципаль районы,**
**Тутай авыл җирлеге**
**Советрәисе** **Н.М.Насретдинова**